ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘСӘДЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ
423753,Мәсәде авылы,
Нефтяников ур.,18нче йорт
Тел.3-44-49.
e-mail: masad.akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ МАСАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423753,деревня Масады,
ул.Нефтяников,дом 18,
тел.3-44-49.
e-mail: masad.akt@yandex.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**06.04.2026ел** **№7**

**Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 15 февралендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Актаныш районы прокурорының 27.03.2026 ел № 02-08-02-2026/Прдп 132-26-20920005, номерлы протестын карап, Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл башкарма комитеты хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе Кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 15 февралендәге 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кисәккә түбәндәге эчтәлекле 2.14_1 пунктчасы өстәргә:

«2.14_1. Һәлак булган (вафат булган) сугышчан хәрәкәтләр ветеранының кабат никахка кермәгән (өйләнмәгән) хатыны (ире) белән хезмәт шартнамәсен эш бирүче инициативасы белән өзү сугышчан хәрәкәтләр ветераны һәлак булган (үлгән) мизгелдән соң бер ел дәвамында рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы беренче өлешенең 1, 5 - 8, 10 яисә 11 пунктларында яисә 336 статьясындагы 2 пунктында каралган нигезләр буенча эштән азат ителүдән тыш).»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Гатин И.Т.